РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39
тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
28.04.2020

**КАРАР**
№ 217

**«Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системасын эшләү һәм куллану тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 3 мартындагы 89 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында**

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында»гы 2006 елның 27 июлендәге149-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында»гы 2013 елның 28 ноябрендәге 1091 номерлы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системасын эшләү һәм куллану тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 3 мартындагы 89 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2) сатып алуларның идентификацион кодлары турындагы мәгълүматның туры килүен

һәм әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс тәэминаты күләменең артмавын контрольдә тоту:

- сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә, план-графикларда булган;

- сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә булган мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләре турында;

- «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә, контрактлар төзелә торган сатып алуларда катнашучыларга бердәм мәгълүмат системасын кулланып, җибәрелә торган контрактлар проектлары - тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә булган мәгълүмат);

в) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында»гы Федераль закон тарафыннан каралган электрон култамга электрон документларына кул кую өчен куллану;

г) бердәм мәгълүмат системасында булган мәгълүматны һәм документларны саклау срогы дәвамында электрон имзаны тикшерү мөмкинлеге;

д) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль законда һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында»гы Федераль законда каралган мәгълүматларны һәм документларны урнаштыру;

е) Россия Федерациясе законнарында һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында башка норматив хокукый актларда каралган электрон документлар, сатып алулар өлкәсендә контракт системасында катнашучылар арасында «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мөнәсәбәтләр кысаларында сатып алулар өлкәсендә контракт системасында катнашучылар арасында алмашу;

ж) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр каталогын формалаштыру һәм алып бару;

з) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру мөмкинлеге;

и) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнарының, инновацион продукция, югары технологияле продукция, дару чаралары сатып алу планнарының, мондый планнарга кертелгән үзгәрешләр проектларының, шулай ук аерым төр юридик затларның «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында»гы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алуларда катнашуы турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүенә мониторинг һәм бәяләү мөмкинлеге;

к) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә сатып алулар турында мәгълүматны анализлау һәм бәяләү мөмкинлеге;

л) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль законның 99 статьясында каралган контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бердәм мәгълүмат системасында булган мәгълүматны һәм документларны алу мөмкинлеге. 3.2. Сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларының эшләү һәм куллану тәртибе, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында»гы 2013 елның 28 ноябрендәге 1091 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне һәм таләпләрне исәпкә алып, әлеге нигезләмә белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Хисамовага йөкләргә.

**Тәтеш муниципаль районы**

**башкарма комитеты**

**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**